ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**04.05.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1072**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 1919 номерлы карары белән расланган, төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон, 2021 елның 30 декабрендәге«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 476-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы карары белән расланган, төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 бүлеге 2.5.1. пунктынының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) капиталь төзелеш объектын реконструкцияләгән очракта, капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы, әлеге өлешнең 6.2 пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортны реконструкцияләү очракларыннан тыш, блокланган төзелештәге барлык йортларның да бер рәттә төзекләндерелгән йортларның хокукка ия булучыларының ризалыгы».

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында ((http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев